Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлеге Башлыгы
КАРАРЫ

17 ноябрь, 2021 ел № 3

Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06.10.131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Күн авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 08 ноябрендәге 141 номерлы Күн авыл җирлеге Советы карары нигезендә карар бирәм:

1. Күн авыл җирлегендә түбәндәге торак пунктларда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләргә:

1.1. Күн авылында. Халык җыенын алты этапта уздырырга:

- гражданнар җыенының беренче этабы 2021 елның 2 декабрендә 9.00 сәгатьтә Совет урамы, 61а йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасы янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Яңа, Урман, Мәктәп урамнары йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының икенче этабы 2021 елның 2 декабрендә 11.00 сәгатьтә Совет урамы, 61а йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасы янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Кави Шакиров урамы йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының өченче этабы 2021 елның 2 декабрендә 14.00 сәгатьтә Совет урамы, 61а йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасы янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Совет урамының 1-56 йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының өченче этабы 2021 елның 2 декабрендә 14.00 сәгатьтә Совет урамы, 61а йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасы янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Совет урамының 1-56 йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының дүртенче этабы 2021 елның 3 декабрендә 9.00 сәгатьтә Совет урамы, 61а йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасы янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Совет урамы буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының бишенче этабы 2021 елның 3 декабрендә 11.00 сәгатьтә Совет урамы, 61а йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасы янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә М.Конов урамы, Комсомол урамы буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының алтынчы этабы 2021 елның 3 декабрендә 14.00 сәгатьтә Совет урамы, 61а йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасы янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Пионер урамы, Тукай урамы буенча теркәлгән кешеләрне кертергә.

«Сез, 2022 елда Күн торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге уку формасы студентларын, 90 яшьтән өлкәнрәк кешеләрне бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

«РИЗА» «КАРШЫ».

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү

1.2. Кызыл Яшьләр авылында. 2022 елның 4 декабрендә 8.00 сәгатьтә Колхоз урамындагы 9 нчы йорт янында гражданнар җыенын үткәрергә

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2022 елда Күн авыл җирлеге Кызыл Яшьләр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге уку формасы студентларын, 90 яшьтән өлкәнрәк кешеләрне бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- су белән тәэмин итү системасын урнаштыру

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.3. Әлбәдән авылында. Гражданнар җыенын 2021 елның 4 декабрендә 10.00 сәгать Күл буе урамы, 25а йорт адресы буенча урнашкан ФАП бинасы янында үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2022 елда Әлбәдән торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау;

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Күн авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлеге башлыгы

Р.Г. Баһауов